СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**«19»нчы октябрь 2020 ел** **№ 9**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

2019 елның 01 апрелендәге 48-ФЗ номерлы «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Хезмәт кодексына электрон рәвештә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр булдыру өлешендә үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2018 елның 11 июлендәге 227 нче номерлы карары (29.10.2018 № 258 кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 12 пункт:

1) 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ рәвешендә;».

2) 5 пунктчаның 1 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хезмәт кенәгәсенең күчермәсе һәм (яисә) хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66_1 статьясы), хезмәт шартнамәсе беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Совет рәисе,
Муниципаль район Башлыгы Р.Г. Кәлимуллин